ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 гыйнвар 2025 ел № 359

Башкарма комитетның 2021 елның 20 гыйнварындагы 264 номерлы Карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 20 гыйнварындагы 264 номерлы Карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен бюджет һәм автономияле учреждениеләргә субсидияләр бирү күләмен һәм шартын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 пунктта «хисап елыннан соң килүче елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «хисап елыннан соң килүче елның 20 гыйнварыннан соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 пунктта «беренче 15» сүзләрен «30» цифрына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ